ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

01 ноября 2017 г. № 6671

Сатулар үткәрмичә җир кишәрлеген сату-алу килешүе төзегәндә, Яр Чаллы шәһәре муниципаль милкендә урнашкан җир кишәрлекләрен сату бәясен билгеләү тәртибен билгеләү турында

Россия Федерациясе Җир кодексының 39.4 маддәсендәге 2 пунктның 3 пунктчасы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ санлы Федераль закон, Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Уставының 28 маддәсе нигезендә

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. Сатулар үткәрмичә җир кишәрлеген сату-алу килешүе төзегәндә, Яр Чаллы шәһәре муниципаль милкендә урнашкан җир кишәрлекләрен сату бәясен билгеләү тәртибен кушымтада каралганча билгеләргә.

2. Башкарма комитетның җир һәм мөлкәти мөнәсәбәтләр идарәсе башлыгы Л.Р. Гыйззәтуллинга әлеге карарны «Челнинские известия» газетасында бастыруны, «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) һәм шәһәрнең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Башкарма комитетның җир һәм мөлкәти мөнәсәбәтләр идарәсе башлыгы Л.Р. Гыйззәтуллинга йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Р.Ә. Абдуллин

Башкарма комитетның
2017 елның 1 ноябрендәге
6671 нче карарына
кушымта

Сатулар үткәрмичә җир кишәрлеген сату-алу килешүе төзегәндә,
Яр Чаллы шәһәре муниципаль милкендә урнашкан җир кишәрлекләрен
сату бәясен билгеләү
тәртибе

1. Әлеге тәртип Россия Федерациясе Җир кодексының 39.3 маддәсенең 2 пункты нигезендә, сатулар үткәрмичә җир кишәрлеген сату-алу килешүе төзегәндә, Яр Чаллы шәһәре муниципаль милкендә урнашкан җир кишәрлекләрен сату бәясен билгели.

2. Базар бәясенә тигез, ләкин җир кишәрлегенең кадастр бәясеннән артмаган бәя белән түбәндәгеләрне сату гамәлгә ашырыла:

1) территорияне комплекслы үзләштерү өчен арендага бирелгән җир кишәрлегеннән барлыкка килгән җир кишәрлекләрен (эконом класслы торак төзү максатында территорияне комплекслы үзләштерү турында килешү төзегән юридик затка, шундый торак төзү максатында территорияне комплекслы үзләштерү өчен арендага бирелгән җир кишәрлегеннән барлыкка килгән җир кишәрлекләреннән тыш) Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы нигезендә, территорияне комплекслы үзләштерү турында килешү төзегән затка;

2) «Торак төзелеше үсешенә ярдәм күрсәтү» 2008 елның 24 июлендәге 161-ФЗ санлы Федераль закон нигезендә, территорияне комплекслы үзләштерү максатында төзелгән аренда килешүе яки түләүсез файдалану килешүе буенча бирелгән җир кишәрлегеннән барлыкка килгән җир кишәрлекләрен;

3) индивидуаль торак төзелеше максатында территорияне комплекслы үзләштерү өчен гражданнар тарафыннан төзелгән коммерцияле булмаган оешмага бирелгән җир кишәрлекләреннән барлыкка килгән җир кишәрлекләрен (гомуми файдаланудагы мөлкәткә караган җир кишәрлекләреннән тыш) әлеге коммерцияле булмаган оешма әгъзаларына яки, әгәр ул әлеге коммерцияле булмаган оешма әгъзаларының гомуми җыелышы карарында каралса, әлеге коммерцияле булмаган оешмага;

4) бакчачылык, яшелчәчелек, дача хуҗалыгы алып бару өчен гражданнар тарафыннан төзелгән коммерцияле булмаган оешмага бирелгән җир кишәрлегеннән барлыкка килгән җир кишәрлекләрен (гомуми файдаланудагы мөлкәткә караган җир кишәрлекләреннән тыш) әлеге коммерцияле булмаган оешма әгъзаларына;

5) юридик затларның даими (вакыты чикләнмәгән) файдалануында булган җир кишәрлекләрен (әлеге җир кишәрлекләрендә биналар, корылмалар булмаган очракта) алда әйтелгән юридик затларга (Россия Федерациясе Җир кодексының 39.9 маддәсенең 2 пунктында күрсәтелгән затлардан тыш);

6) Россия Федерациясе Җир кодексының 39.18 маддәсе нигезендә, җир кишәрлекләрен гражданнарга индивидуаль торак төзелеше, торак пункт чикләрендә шәхси ярдәмче хуҗалык, бакчачылык, дача хуҗалыгы алып бару өчен.

3. Җир кишәрлегенең кадастр бәясеннән унбиш процентка тигез бәя белән түбәндәгеләрне сату гамәлгә ашырыла:

1) индивидуаль торак төзелеше максатларында, территорияне комплекслы үзләштерү өчен гражданнар тарафыннан төзелгән коммерцияле булмаган оешмага бирелгән һәм гомуми файдаланудагы мөлкәткә караган җир кишәрлеген бүлү нәтиҗәсендә барлыкка килгән җир кишәрлекләрен әлеге коммерцияле булмаган оешмага;

2) дача хуҗалыгы алып бару өчен юридик затка бирелгән һәм гомуми файдаланудагы мөлкәткә караган җир кишәрлеген бүлү нәтиҗәсендә барлыкка килгән җир кишәрлекләрен әлеге юридик затка.

4. Россия Федерациясе Җир кодексының 39.20 маддәсендә каралган очракларда, биналар, корылмалар урнашкан җир кишәрлекләрен шул биналарның, корылмаларның яисә андагы бүлмәләрнең милекчеләренә саткан очракта, җир кишәрлеген сату бәясе түбәндәге формула буенча билгеләнә:

Ц= ЗН х К, монда:

Ц – җир кишәрлеген сату бәясе;

ЗН – җир кишәрлеге өчен җир салымы (календарь ел өчен җир кишәрлеге өчен җир салымының билгеләнгән тәртиптә исәпләнгән суммасы);

К – җир кишәрлеге өчен җир салымына кабатлы коэффициент, 17 гә тигез.

Җир кишәрлеге өчен җир салымы түбәндәге формула буенча исәпләнә:

ЗН=КС х СЗН, монда:

ЗН – җир кишәрлеге өчен җир салымы;

КС – җир кишәрлегенең кадастр бәясе;

СЗН – җир салымының Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Шәһәр Советы карары белән билгеләнгән һәм җир салымы буенча ташламалар исәпкә алынмаган салым күләме.

5. Җир кишәрлеген сату бәясе җир кишәрлеген милеккә бирү турында гариза бирелә торган датага билгеләнә.

Башкарма комитет
Аппараты Җитәкчесе

Г. К. Әхмәтова